РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
Татарско-Шуганского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай
муниципаль районы Татар Шуган
авыл җирлеге Советы
БАШЛЫГЫ

ул. Советская, д. 41в , село Татарский
Шуган, Азнакаевского
муниципального района, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

Совет урамы, 41в, Татар Шуган
авылы, Азнакай муниципаль районы,
423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «08 » ноябрь 2022ел №5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Татар Шуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджет проекты турында фикер алышуда катнашу өчен ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10. 2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татар Шуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Советының 19.04.2012 ел № 44 (27.01.2015 ел №127, 04.09.2015 ел №152, 04.03.2016 ел №29, 30.03.2018 ел №91 карарлар редакциясендә) карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Халык алдында тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2021 елның 29 ноябре 16.00 сәгатьтә;

- үткәрү урыны- Татар Шуган авыл мәдәният йорты;

- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес: Татар Шуган авылы, Совет урам, 41в йорт.

4. Гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегенең норматив хокукый актлары һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru.) 2022 елның 10 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык М.Ш.Хәертдинов